ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

**(V чакырылыш)**

Чираттан тыш утырыш

«25» декабрь 2025 ел № 9 Олы Мишә ав.

Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының 15.11.2023 ел № 99 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының 15.11.2023 ел № 99 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (29.07.2024 № 115; 24.10.2024 № 121 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2.1 пунктчасын «билгеләнешен проектлаучы күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы

Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы: Ф.Б.Җамалетдинов